МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.07.2015 г.Казань № 346

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 мартындагы 96нчы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының төсле металл, кара металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензион контрольне башкару буенча дәүләт функциясен үтәвенең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга яраштыру максатында, һәм шулай ук «Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турындагы кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контрольне башкару өлешендә дәүләт органнарының һәм муниципаль органнарның вәкаләтләрен төгәлләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуларын тану хакында» 2014 елның 14 октябрендәге 307-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатында **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 мартындагы 96нчы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының төсле металл, кара металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензион контрольне башкару буенча дәүләт функциясен үтәвенең административ регламентына кертелә торган әлеге боерыкка теркәлгән үзгәрешләрне (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2015 елның 19 мартындагы 135нче боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расларга.

2. Дәүләт мәгълүмат ресурслары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара эш итү бүлегенә (Т.А.Апаевка) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешенә контрольлек итүне министр урынбасары А.Д.Шәмсиевкә йөкләргә.

**Министр** **А.А.Здунов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгы
боерыгы белән расланган
28.07.2015 № 346

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 мартындагы 96нчы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының төсле металл, кара металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензион контрольне башкару буенча дәүләт функциясен үтәвенең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр**

Административ регламентның 1 бүлеге 1.6.3 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 8 һәм 9 пунктчалар белән тулыландырырга:

«8) СССР һәм РСФСР башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары белән билгеләнгән һәм Россия Федерациясе законнарына туры килми торган таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

9) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә басылмаган, хокукый актлар белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тикшерергә.».